| КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 15 август № 564

г. Казань

«Россиянең мактаулы доноры» («СССРның мактаулы доноры») күкрәк билгесе белән бүләкләнгән затларга еллык акчалата түләүне гамәлгә ашыру буенча Россия Федерациясенең тапшырылган вәкаләтен тормышка ашыру өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына субвенцияләрне тоту кагыйдәләрен раслау турында

«Кан һәм аның компонентлары донорлыгы турында» 2012 елның 20 июлендәге 125-ФЗ номерлы Федераль законның 25 статьясын тормышка ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Теркәлгән «Россиянең мактаулы доноры» («СССРның мактаулы доноры») күкрәк билгесе белән бүләкләнгән затларга еллык акчалата түләүне гамәлгә ашыру буенча Россия Федерациясенең тапшырылган вәкаләтен тормышка ашыру өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына субвенцияләрне тоту кагыйдәләрен расларга.

2. Түбәндәгеләр үз көчен югалтуын танырга:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «СССРның мактаулы доноры», «Россиянең мактаулы доноры» билгеләре белән бүләкләнгән затларга социаль ярдәм күрсәтү чараларын тәэмин итү өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына субвенцияләр рәвешендә бирелә торган акчаны тоту кагыйдәләрен раслау турында» 2008 ел, 7 апрель, 212 нче карары;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 12 март, 157 нче карарының 6 пункты.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 15 август, 564 нче карары белән расланды

«Россиянең мактаулы доноры» («СССРның мактаулы доноры») күкрәк билгесе белән бүләкләнгән затларга еллык акчалата түләүне гамәлгә ашыру буенча Россия Федерациясенең тапшырылган вәкаләтен тормышка ашыру өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына субвенцияләрне тоту кагыйдәләре

1. Әлеге Кагыйдәләр «Россиянең мактаулы доноры» («СССРның мактаулы доноры») күкрәк билгесе белән бүләкләнгән затларга еллык акчалата түләүне гамәлгә ашыру буенча Россия Федерациясенең тапшырылган вәкаләтен тормышка ашыру өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына субвенцияләрне (алга таба – субвенцияләр) тоту тәртибен билгели.

2. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсеннән (алга таба – Казначылык) бюджет йөкләмәләре лимитлары һәм финанслауның чик күләмнәре турында мәгълүматны алганнан соң эш көннәрендә исәпләнгән 10 көн эчендә Казначылыкка Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына (алга таба – Министрлык) финанслауның чик күләмнәренә җиткерүгә чыгым тәртибен тапшыра.

3. Чыгым субвенцияләре Министрлык тарафыннан Казначылыкта ачылган шәхси счет аша гамәлгә ашырыла.

4. Министрлык Казначылыктан финанслауның чик күләмнәренә җиткерүгә чыгым тәртибен алганнан соң эш көннәрендә исәпләнгән 10 көн эчендә Казначылыкка алга таба «Россиянең мактаулы доноры» («СССРның мактаулы доноры») күкрәк билгесе белән бүләкләнгән затларга еллык акчалата түләүне гамәлгә ашыру өчен «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесенә (алга таба – Үзәк) субвенция акчасын күчерү өчен касса чыгымына заявка тапшыра.

5. Субвенцияләр исәбеннән түбәндәгеләр башкарыла:

«Россиянең мактаулы доноры» («СССРның мактаулы доноры») күкрәк билгесе белән бүләкләнгән затларга еллык акчалата түләүне алып барып бирү буенча чыгымнарны түләү;

«Россиянең мактаулы доноры» («СССРның мактаулы доноры») күкрәк билгесе белән бүләкләнгән затларга еллык акчалата түләүне гамәлгә ашыру буенча Россия Федерациясенең тапшырылган вәкаләтләрен тормышка ашыру белән бәйле Министрлык һәм Үзәк эшчәнлеген тәэмин итүгә чыгымнар компенсациясе.

6. Үзәк квартал саен, хисап чорыннан соң килә торган айның 10 көненнән дә соңга калмыйча, һәм ел саен, хисап елының 1 декабренә кадәр һәм хисап елыннан соң килә торган елның 15 гыйнварына кадәр Министрлыкка Федераль медицина-биология агентлыгы раслаган форма буенча Татарстан Республикасы бюджетының

«Россиянең мактаулы доноры» («СССРның мактаулы доноры») күкрәк билгесе белән бүләкләнгән затларга еллык акчалата түләүне гамәлгә ашыру белән бәйле башкарылган чыгымнары турында хисап тапшыра.

7. Министрлык:

квартал саен, хисап чорыннан соң килә торган айның 15 көненнән дә соңга калмыйча, Федераль медицина-биология агентлыгына һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына Федераль медицина-биология агентлыгы раслаган форма буенча Татарстан Республикасы бюджетының «Россиянең мактаулы доноры» («СССРның мактаулы доноры») күкрәк билгесе белән бүләкләнгән затларга еллык акчалата түләүне гамәлгә ашыру белән бәйле башкарылган чыгымнары турында хисап тапшыра;

ел саен, хисап елының 5 декабренә кадәр, хисап елыннан соң килә торган елның 1 гыйнвары торышына, гыйнвар – ноябрьгә гамәлдәге чыгымнардан һәм хисап елының декабрендә планлаштырыла торган чыгымнардан чыгып, Федераль медицина-биология агентлыгына һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына Федераль медицина-биология агентлыгы раслаган форма буенча Татарстан Республикасы бюджетының «Россиянең мактаулы доноры» («СССРның мактаулы доноры») күкрәк билгесе белән бүләкләнгән затларга еллык акчалата түләүне гамәлгә ашыру белән бәйле башкарылган чыгымнары турында хисап тапшыра;

ел саен, хисап елыннан соң килә торган елның 20 гыйнварыннан соңга калмыйча, Федераль медицина-биология агентлыгына һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына Федераль медицина-биология агентлыгы раслаган форма буенча Татарстан Республикасы бюджетының «Россиянең мактаулы доноры» («СССРның мактаулы доноры») күкрәк билгесе белән бүләкләнгән затларга еллык акчалата түләүне гамәлгә ашыру белән бәйле башкарылган чыгымнары турында еллык хисап тапшыра.

8. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы квартал саен, хисап чорыннан соң килә торган айның 5 көненнән дә соңга калмыйча, Министрлыкка һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округларында «Россиянең мактаулы доноры» («СССРның мактаулы доноры») күкрәк билгесе белән бүләкләнгән гражданнар саны турында мәгълүматлар тапшыра.

9. Министрлык һәм Үзәк хисап тапшырылган мәгълүматларының дөреслеге һәм субвенцияләрне максатчан файдаланмау өчен законнар нигезендә җавап тота.

10. Субвенцияләрне максатчан файдаланмау Россия Федерациясе бюджет законнары нигезендә җаваплылыкка алып килә.

11. Субвенцияләрне максатчан файдалануны тикшерүдә тотуны Министрлык һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы законнар нигезендә гамәлгә ашыра.